ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.09.2019 с. Верхний Услон 890

**Татарстан Республикасы**
**Югары Ослан муниципаль районында**
**2019-2020 уку елына мәктәп автобус маршрутларын**
**эксплуатацияләүне яңарту турында**

Югары Ослан муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын уку урынына куркынычсыз һәм өзлексез транспорт белән китереп җиткерүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәп автобус маршрутын ачу турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2010 ел, 3 август, №615 карарын үтәү йөзеннән, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Муниципалитет эчендәге автобус маршрутларын эксплуатацияләүне яңартырга:

№1 Макулово – Маматкозино – Макулово – АЗС – Сеитово – Макулово;
№2 Макулово – Соболевское – Карамышиха – Клянчино - Макулово – АЗС – Макулово;
№3 Коргуза – АЗС – Ямбулатово – Егидерево – Коргуза;
№4 Верхний Услон – пос. им. Кирова – Верхний Услон – Печищи – Верхний Услон;
№5 Куралово – Исаково – Савино – В. Слобода – Тат. Бурнашево – Русское Бурнашево – Куралово;
№6 Большие Меми – Заборная Поляна – Большие Меми – Майдан - Канаш – Большие Меми – Заборная Поляна – Канаш – Майдан – АЗС - Большие Меми;
№7 Октябрьский – Ташевка – Вахитова –Ватан - Янги- Болгары – Никольский – АЗС (с.В.Услон) – Октябрьский;
№8 Коргуза – АЗС – Патрикеево – Харино – Кильдеево – Коргуза; Коргуза – Кильдеево – Харино – Патрикеево – Коргуза;
№9 Бакча-Сарай — Брек – Янга Юл – Вахитова –Ташевка – Матюшино – Бакча-Сарай – АЗС (В.Услон) – Ключищи – Н. Услон – Октябрьский – Янги Болгары – Бакча-Сарай;
№10 Верхний Услон – АЗС - Ключищи - Нижний Услон - Студенец - Кирова – Печищи - Верхний Услон;
№11 Набережные Моркваши - АЗС (с. В.Услон) - Лесные Моркваши - Фурцево – Покровка - Пустые Моркваши – Пятидворка - Набережные Моркваши;

№12 Шеланга- АЗС(с.В. Услон)- Янга Юл -Нариман – Кзыл Байрак-пос.Кирпичного завода- ООО “Керамика Синтез”-Шеланга;

2. Мәктәп автобусларының хәрәкәт итү графигын расларга (№1-12 Кушымта)

3. «Макуловская СОШ», «Коргузинская СОШ», «Верхнеуслонская гимназия», «Кураловская СОШ», «Большемеминская СОШ», «Октябрьская СОШ», «Матюшинская СОШ», «Верхнеуслонская СОШ», «Набережно – Морквашская СОШ», «Шеланговская СОШ» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә 2019 елның 1 сентябренә кадәр җаваплы кешеләр билгеләргә:

- транспортта үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәтү буенча укучылар белән махсус дәресләр үткәрү өчен;

- автобус хәрәкәте чорында балаларны маршрут буенча озата бару өчен.

4. «Татавтодор» ААҖ №5 Югары Ослан участогының Апас филиалына, юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры китереп, мәктәп автобусы маршрутында укучыларны утырту һәм төшерү пунктларын карап тоту һәм ремонтлау буенча өстәмә эшләр башкарырга тәкъдим итәргә.

5. РФ Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлеге ЮХИДИ бүлеге Башлыгына әлеге маршрутларда юлларның торышын һәм юл хәрәкәте куркынычсызлыгын контрольдә тотуны тәкъдим итәргә.

6. Финанс-бюджет палатасы рәисе Е.Е. Колесовага балаларны мәктәп автобуслары белән йөртүне оештыру өчен кирәкле акча бүлеп бирергә.

7. МКУ «ТР Югары Ослан районы мәгариф бүлеге» социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИССО) куллану юлы белән һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә «мәктәп автобусларында балаларны түләүсез йөртү» ташламалары бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

«Мәктәп автобусларында балаларны түләүсез йөртү» ташламалары турында мәгълүмат ЕГИССО Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә куллану юлы белән һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматларга туры китереп алынырга мөмкин.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Башкарма комитет Җитәкчесе** **В.С. Тимиряев**